5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Сиякина Н. Р. «Туган телем – халкым теле» этномәдәни проектын мәктәп шартларында тормышка ашыру // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 2 (21).
URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/07/2024_2_siyakina.pdf

УДК 37.01

**Нәфисә Равиловна Сиякина**
югары категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы «Генерал-майор Хапаев Владимир Аверкий улы исемендәге Тәтеш кадет-интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү мәктәбе Тәтеш шәһәре, Татарстан

# «Туган телем – халкым теле» этномәдәни проектын мәктәп шартларында тормышка ашыру

***Аннотация.*** В статье раскрывается опыт реализации школьного этнокультурного проекта, разработанного на основе современных образовательных тенденций в процессе обучения родному языку и литературе.
***Ключевые слова***: этнокультурный проект, этническое самосознание, культура межнационального общения, проектная деятельность

**Nafisa R. Siyakina**
Teacher of Native Language and Literature of the highest qualification category, Tetyushi Cadet Boarding School named after the son of Major General Hapaev V.A., Tetyushi district, Republic of Tatarstan, Russia

# Realization of Ethnocultural Project “My Native Language – The Language of My People” in School Conditions

***Abstract.*** The article reveals the experience of implementing a school ethno-cultural project developed on the basis of modern educational trends in terms of updating the national and regional component in the process of teaching native language and literature.
***Keywords:*** ethnocultural project; ethnic identity; project activities; culture of interethnic communication; extracurricular activities

Без яшәгән заман — глобальләшү, тирән үзгәрешләр һәм актив хезмәттәшлек чоры. Мәгълүмати киңлекнең ачыклыгы, белем алу мөмкинлеге үсеше чираттагы мөһим проблемалар тудыра: сизелерлек ассимиляция, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, милли телләрнең югалуы. Билгеле булганча, тел – теге яки бу халкының рухи мирасын буыннан-буынга җиткерүдә төп чара булып тора.

Мәгариф системасында барган үзгәрешләр, аеруча федераль белем бирү стандартлары туган телләрне укытуга яңа таләпләр куя. Нәкъ менә шуңа күрә бүгенге көндә лингвистик һәм коммуникатив компетенция белән беррәттән, этномәдәни компетенция формалаштыруга да игътибар бермә-бер артты. Күпмилләтле җәмгыять шартларында укучыларда этномәдәни компетенцияләр булдыру ысулы — нәтиҗәле кулланыла торган актуаль укыту ысулларының берсе.

Бу өлкәдә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карары нигезендә

© Сиякина Н. Р., 2024

2015–2030 нчы елларга Милли мәгарифне үстерү Концепциясе кабул ителде. Укучыларда туган телебезгә, тарихыбызга һәм Татарстан халыкларының этномәдәни мирасын үзләштерүгә кызыксынуны арттыру — әлеге Концепциянең көтелгән нәтиҗәләренең берсе булып тора. Гомуми белем бирү программасына «Туган тел һәм әдәбият» фәненең ролен бәяләп бетерү мөмкин түгел. Нәкъ менә бу фән без яшәгән төбәгебез һәм илебезнең милли мәдәниятләрен үзара өйрәнү өчен плацдарм булып тора.

Тәтеш кадет-интернат мәктәбендә 2021–2022 елларда этномәдәни юнәлешле «Туган телем — халкым теле» проекты тормышка ашырылды. Проектның авторы буларак эшне мәктәпнең педагогик составы, ата-аналар җәмәгатьчелеге, районның иҗтимагый оешмалары белән берлектә оештырдым. Туган тел һәм әдәбият дәресләре белән беррәттән, мәктәп театрын һәм «Заманча мәктәп» федераль проекты, "Милли мәгариф" республика проекты кысаларында эшләп килгән «Үсеш ноктасы" үзәгендә "Фәнни потенциал" проект эшчәнлеге түгәрәген җитәклим. Шулай итеп, проект эше туган тел һәм әдәбият дәресләре, дәрестән тыш эшчәнлек, фән буенча өстәмә белем бирү аша этнопедагогик киңлектә алып барылды. Проект кысаларында мөһим мәсьәләләр каралды:

1. Туган телдә коммуникатив күнекмәләрне югалту проблемасы: балалар гадәти тормышта милли туган телне сирәгрәк ишетәләр, кайбер балалар ата-аналары белән дә татар телендә сөйләшмиләр.

2. Уку планында татар теле һәм әдәбият сәгатьләренең саны аз булуы: бу укытучыдан укытуның альтернатив мөмкинлекләрен эзләүне таләп итә. Проблеманы хәл итү өчен фән буенча оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек ярдәмгә килә.

3. Халыкларның этник ассимиляциясе проблемасы, рухи-мәдәни байлыгыбызны, милли гореф-гадәтләрне оныту.

Кадет мәктәбендә укыту 5 сыйныфтан рус телендә алып барыла. Туган тел һәм әдәбият дәресләре, ата-аналар теләгән истә тотып, һәр класста алып барыла. Тәрбияләнүчеләрнең 70 % — Татарстанда, 30 % — Россиянең башка төбәкләрендә яши. Читтән килгән укучыларга әлеге проект яшәү мохитенә кушылып китәргә, күптөрлелекне тоярга һәм үз мәдәниятеңне аңларга ярдәм итәр дип фаразланган иде.

Проектның өстенлекле юнәлеше — төбәк һәм ил халыкларының күптөрлелеге белән танышып, аларның шәхси мәдәни кодын аңлау һәм укучыларның этник һәм милли үзаңын формалаштыру. Проектның максаты — укыту-тәрбия процессында укучыларның коммуникатив һәм этномәдәни компетенцияләрен формалаштыру. Максаттан чыгып бурычлар билгеләнде:

1. Укыту-тәрбия процессына инновацион технологияләр (коммуникатив, этномәдәни) кертеп халкыбызның милли-мәдәни мирасын өйрәнүгә җирлек булдыру;

2. Укучылар, ата-аналар һәм партнерлар белән берлектә оештырылган этномәдәни белем бирү мохитендә иҗат мөмкинлекләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән дәресләр, мәктәп театры буенча дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру;

3. Татар язучыларының әдәби мирасы белән бәйле булган темаларны тикшерүгә, туган төбәгебездә яшәгән күренекле шәхесләрне өйрәнүгә басым ясап, «Фәнни потенциал» түгәрәгенең системалы эшен оештыру, олимпиадаларда, иҗади бәйгеләрдә нәтиҗәне яклау этабы булдыру.

**Проектның гамәли әһәмияте**

Проект материалларын туган тел укытучыларының һөнәри дәрәҗәсен үстерү максатыннын семинарларда һәм мастер-классларда кулланып була. «Туган тел һәм әдәбият фәненнән проект эшчәнлеге оештыру» методик әсбабы укытучыларга дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлек вакытында проект һәм эзләнү эшләре алып баруда, бәйрәм һәм конкурслар оештыруда ярдәм итәр.

Проектны тормышка ашыру срогы: 01/01/2021 – 31/12/2022

| Этап | Вакыты | Эш төрләре |
|---|---|---|
| Оештыру | Гыйнвар 2021 | Туган тел һәм әдәбиятны этномәдәни юнәлештә укыту буенча методик материаллар белән танышу, анализлау;<br>Тема буенча интернет-ресурслар контентын булдыру<br>Укучыларның туган тел һәм әдәбиятны өйрәнүгә мотивлаштыруны тикшерү өчен диагностика материаллары төзү, үткәрү;<br>Шәхси сайтны актуальләштерү:<br>https://nsportal.ru/nafisa-siyakina<br>5. Проектның календарь планын төзү. |
| Төп | 02.2021-11.2022 | Тематик дәресләр, милли бәйрәмнәр, иҗади конкурслар, халык иҗаты күргәзмәләре, экскурсияләр үткәрү;<br>Конкурслар һәм конференцияләрдә катнашу,«Туган тел һәм әдәбият фәненнән проект эшчәнлеге оештыру» методик әсбабына материал туплау;<br>Шәхси сайтны методик эшкәртмәләр белән тулыландыру;<br>Китапнамә һәм фильм өчен видео материаллар әзерләү;<br>«Шәвәлинең көлкеле маҗаралары» китапнамәсен төзү<br>https://disk.yandex.ru/i/m2zRy-_MjuI0Dg |
| Йомгаклау | 12.2022 | Туган тел өйрәнүгә мотивлаштыру буенча йомгаклау диагностик тесты үткәрү;<br>Проект буенча нәтиҗәләр чыгару<br>https://nsportal.ru/user/587259/page/tugan-telem-halkym-tele-proekty<br>Уздырылган чаралар буенча видеоролик төшерү: https://disk.yandex.ru/i/NqIdrvO7pEldhw<br>«Туган тел һәм әдәбият фәненнән проект эшчәнлеге оештыру» методик әсбабы бастыру. |

Ике ел проект буенча системалы эш дәверендә зур нәтиҗәләргә ирешелде:

I. Мәктәпнең укыту һәм белем бирү процессына коммуникатив, этномәдәни технологияләре кертә һәм бу очракта туган тел һәм әдәбият фәнен өйрәнүгә кызыксыну һәм белем сыйфаты артты:

1. Туган тел өйрәнүгә мотивацияне тикшерү буенча диагностика нәтиҗәләре: проектка кадәр — 53 %, проекттан соң — 60 %.

2. Республика олимпиадасы нәтиҗәләре

Район этабы: 2021/22 уку елы — Низаметдинов И., 11 кл., призер; 2022/23 уку елы — Зарипов Р., 8 кл., җиңүче; Газизов И., 10 кл., призер.

3. Туган тел һәм әдәбият фәне буенча белем сыйфаты:

2021/22 уку елы — туган тел — 87 %, әдәбият — 90 %

2021/22 уку елы — туган тел — 90 %, әдәбият — 92 %

II. Иҗади һәм интеллектуаль потенциалны үстерүгә ярдәм итә, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә катнашырга этәргеч бирә:

1. “Фәнни потенциал” түгәрәгенә һәм мәктәп театр коллективына йөрүчеләр саны арта: 2021 ел — 14/7; 2022 ел — 15/22.

2. Бу юнәлештәге санлы нәтиҗәләр:

| № | Эш төрләре | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|
| 1 | Туган тел һәм әдәбият буенча дәресләр, мастер-класслар | 8 | 6 |
| 2 | Бәйрәмнәр | 5 | 4 |
| 3 | Дәрестән тыш чаралар | 5 | 4 |
| 4 | Акцияләр | 3 | 2 |
| 5 | Мәктәптән тыш уздырылган чаралар | 13 | 11 |
| | Барлыгы | 35 | 26 |

| Дәрәҗә | 2021 | 2022 |
|---|---|---|
| Халыкара | 2 | 3 |
| Төбәкара | - | 1 |
| Республика | 5 | 5 |
| Зона/Район | 2/2 | 2/2 |

Проект нәтиҗәлеген бәяләү

| **Критерийлар** | **Күрсәткеч** |
|---|---|
| Укыту | 1. Туган тел һәм әдәбият фәнен өйрәнүгә кызыксыну арта;<br>2. “Туган (татар) тел һәм әдәбият” буенча белем сыйфаты арта;<br>3. Иҗади һәм интеллектуаль потенциалны үстерүгә ярдәм итә;<br>4.Укучыларда коммуникатив, этномәдәни компетенцияләр формалаштыра |
| Программа һәм методик кулланмалар | 1. Дәрес эшкәртмәләре, үткәрелгән чараларның сценарийлары төзелә<br>2. “Туган тел һәм әдәбият фәненнән проект эшчәнлеге оештыру” методик әсбабы булдырыла. |
| Укучыларны уку-тәрбия процессына җәлеп итүче чаралар | 1. Дәресләрдә проект темасы белән бәйле эзләнү эшләре, иҗади биремнәр;<br>2. Туган телдә милли бәйрәмнәр, бәйгеләр, халык уеннары;<br>3. Мәктәп театрында туган телдә тамаша күрсәтү;<br>4. Халык иҗаты күргәзмәләре, театрга һәм музейларга экскурсияләр;<br>5. Фәнни-эзләнү эшләре, гамәли конференцияләр. |
| Укучыларга | 1. Укучылар үз-үзләрен оештыру һәм үстерү процессына кертелә, социальләштерелә;<br>2. Туган телне өйрәнүгә уңай мотивация, милли үзаң үстерелә; |
| Мәктәп өчен | 1. Тәтеш кадет-интернат мәктәбенең төп белем бирү программаларының региональ һәм этнокультура өлешен тормышка ашыру;<br>2. Тәрбия программасының 1, 3, 6, 8–10 модульләрен тормышка ашыру. |
| Ата-аналарга | 1. Бәйрәмнәрдә, конкурсларда балалар белән бергә катнашу өчен әзерлек эшләрен оештыру;<br>2. Туган телдә «укытучы-бала-ата-ана» арасында тотрыклы һәм уңайлы аралашу өчен шартлар тудыру. |

Кулланылган әдәбият
1. Поштарева, Т.В. Формирование этнокультурной компетентности / Т.В. Поштарева // Педагогика. — 2005. — № 3.
2. Шәймәрданов, Р.Х. Татар милли педагогикасы / Р.Х. Шәймәрданов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. — Казан, 2007. — 399 б.
3. Шәкүрова, М.М. Татар телен укыту методикасы: теория һәм практика: уку-укыту ярдәмлеге / М.М. Шәкүрова. — Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшр., 2009. — 168 б.

References
1. Poshtareva T.V. Formation of ethnocultural competence. *Pedagogika=Pedagogy Journal*. 2005;(3).
2. Shaimardanov R.KH., A.N. Khuziakhmetov. Tatar National Pedagogy. Kazan, 2007;399 p. (In tatar.)
3. Shakurova M.M. Methods of teaching Tatar language: theory and practice. Kazan: Kazan State University Publ., 2009. 168 p. (In tatar.)